**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2025 Исәнбай авылы № 58-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 26.11.2019 елның 53-1 номерлы Исәнбай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 26.11.2019 елның 53-1 номерлы Исәнбай авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 39 статьяның 1 пунктындагы 13 абзацында «паспортлар тапшырыла» сүзләрен «паспортлар (паспорт проектлары) тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 42 статьяның 3 пунктындагы 14 абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 42 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа уникенче абзац өстәргә:

«бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

Уникенче - унөченче абзацлар тиешенчә унөченче - ундүртенче абзацлар булып санала.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегенең махсус бирелгән мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мөхәммәдиев